СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №79 (7252) | 2 июль, 1991 ел. СИШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен.

## Район кооператорларына

КАДЕРЛЕ ИПТӘШЛӘР!

Халык депутатларының Октябрь район Советы президиумы, КПСС райкомы сезне профессиональ бәйрәмегез—кооперация көне белән кайнар тәбрикли.

Сәүдә, җәмәгать туклануы предприятиеләре, азык-төлек комбинаты һәм райзаготпром коллективлары профессиональ бәйрәмнәре—Халыкара кооперация көнен әйбәт күрсәткечләр белән каршылыйлар. Райпо барлык төр эшчәнлек буенча беренче яртыеллык планнарын уңышлы үтәде.

Әмма без бүген сатып алучыларның сәүдә работниклары хезмәтеннән канәгать түгеллеген исәпкә алырга, производство һәм кооперация сәүдәсе буенча гомуми күрсәткечләрнең безне канәгатьләндермәвен исәпкә алырга тиешбез.

Район Советы президиумы һәм КПСС райкомы Октябрь райпосы работникларының үз алларына куелган бурычларны намус белән башкарып чыгу өчен барлык көчләрен, тәҗрибәләрен һәм белемнәрен куячакларына ышана.

Кооператорлар эшләргә сәләтле, моңа без барыбыз да ышанабыз. Без сезнең сәүдә хезмәте күрсәтүдә халык ихтыяҗларын канәгатьләндерү, аны яхшырту, авыл һәм шәһәр халкын азык-төлек, промышленность һәм катлаулы көнкүреш товарлары белән тәэмин итүдә барлык резервларны тулы файдалану өчен тырышачагыгызга ышанабыз.

Сезгә җаваплы хезмәтегездә зур уңышлар, сәламәтлек һәм бәхет теләп калабыз.

ХАЛЫК ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ РАЙОН СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ.
КПССНЫҢ ОКТЯБРЬ РАЙКОМЫ.



«Чишмә» колхозының товарлыклы-сөтчелек фермасында алдынгылар байтак. Шундыйлардан, сыер савучы Саҗидә Миннәхмәтовна Хәсәнҗанова һәм профилакторий группасында 20 көнгә кадәрге бозауларны караучы, шул ук вакытта тудыру бүлегендә сыерлар да савучы Гөлсинә Шакирҗановна Миннехәерованы атап үтәргә була.

Саҗидә Миннәхмәтовна агымдагы елның алты аенда үз карамагындагы һәр сыердан уртача 1499 килограмм сөт сауды.

Бозау караучы Гөлсинә Шакирҗановнаның да хезмәтенә тел-теш тидерерлек түгел. Июнь аенда ул профилакторий группасындагы бозаулардан 862 шәр грамм уртача тәүлеклек үсеш алды.

Рәсемдә: «Чишмә» колхозы сыер савучысы С. М. Хәсәнҗанова һәм бозау караучы Г. Ш. Минхәерова.

## Котлау телеграммасы

Чувашия Бөтенсоюз иҗтимагый мәдәният үзәге «Туслах» газетасы редакциясен, бөтен авторлар коллективын газетаның данлы алтмыш еллыгы белән кайнар котлый, яңа уңышлар, күп милләтле мәдәниятның чәчәк атуын тели.

М. ЮХМА,
ЧОКЦ идарәсе председателе.

## Сыйфатлы сөт тапшыралар

«Үрнәк» колхозының товарлыклы-сөтчелек фермасы хезмәтчәннәре маллардан яхшы сыйфатлы продукция алуга ирешәләр. Әйтик, май аенда коллектив сөт-май заводына гел беренче сорт сөт кенә озаткан иде. Бу айны да сыйфатсыз продукция озатуга юл куймаска исәпләре.

Товарлыклы - сөтчелек фермасында сыер савучылар арасында оештырылган ярышта Роза Камалиева лидерлыкны үз кулында тота. Ул һәр сыердан тәүлегенә уртача 18 килограмм сөт сава. Сыер савучылар Асия Мотыйгуллина, Фәүзия Шәйхиева аңардан азга гына калышалар. Аларның һәр сыердан савып алган көнлек сөтләре—17,5 килограмм.

И. ШӘЙХИЕВ.

### Игътибар: газета юбилей үткәрә

## Хөрмәтле газета укучылар!

Мәгълүм булганча, 1991 елның 6 июлендә «Дуслык» («Дружба», «Туслах») район газетасы үзенең 60 еллык юбилеен билгеләп үтәчәк. Бу көнне шәһәрнең үзәк мәйданында зур бәйрәм үткәрелә.

Ул көнне сезнең игътибарга 8.00 сәгатьтә—җирле радионың махсус чыгарылышы (ул район буенча трансляцияләнә);

8.30 сәгатьтә культура программасы—район үзешчән сәнгатьтә катнашучылар концерты, тынлы оркестр чыгышы тәкъдим ителә;

9.00 сәгатьтә «Дуслык» газетасы призына төрле күңелле ярышлар: 500 метрга йөгерү, капчык киеп йөгерү, көянтә белән һәм кашык кабып йөгерүләр, аркан тарту, уенчыклар кисү, чүлмәк вату, картингистлар чыгышы, «Дуслык» темасына асфальтта иң яхшы рәсемнәргә конкурс башлана.

10.00 сәгатьтә викторина үткәрелә.

11.00 сәгатьтә район культура йортында зур юбилей тантанасы була. Бу көнне «Норлатнефть» НГДУсы, тимер юлчылар, урман промышленносте хуҗалыгы эшчеләрне тәэмин итү бүлекләре, райпо буфетлары, лареклары һәм «Союзпечать, райпо киосклары эшләячәк.

15.00 сәгатьтә бәйрәм яшьләр өчен культура һәм ял паркында дәвам итәчәк. Анда милли көрәш, капчык сугышы, китап аукционы оештырыла, үзешчән сәнгать көчләре әзерләгән концерт була, барлык аттракционнар һәм буфет эшли.

Бәйрәмгә республика газета һәм журналлары, күрше район газеталары редакторлары, колхоз-совхозлар, предприятие, оешма һәм учреждениеләр җитәкчеләре, партия һәм комсомол оешмалары секретарьлары, авыл Советлары рәисләре, район һәм җәмәгать оешмалары җитәкчеләре, җәмәгать корреспондентлары, «Дуслык» газетасы активистлары кунак булып киләчәк.

Сезне, хөрмәтле укучылар, шулай ук безнең белән газета юбилеен бәйрәм итәргә чакырабыз.

РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

## Бәйрәм алдыннан

**Потребительләр кооперациясе көнен бәйрәм иткәндә, товар әйләнеше һәм авыл хуҗалыгы продукциясен әзерләү күләме буенча республикада беренче урында барган безнең район потребительләр җәмгыяте**

ШАТЛАНА, чөнки былелның биш аенда товар әйләнеше планы үтәлде, азык комбинаты тарафыннан да халык куллану товарларын реализацияләү планы арттырып гамәлгә ашырылды. Ә азык комбинаты каршындагы суган киптерү һәм шикәр-кондитер изделиеләр цехларының республикада эшләп чыгару куәте буенча тиңе юк, 60—70 тонна конфет-драже районда реализацияләнә. Җәмәгать туклануы предприятиесе тарафыннан кондитер-кулинария цехында продукция чыгару өчен кирәкле продуктлар запасы әзерләнде, кибетләрдә маргарин талонсыз сатыла. Шатлана, чөнки Мамык кирпеч заводы җәмәгать туклануы каршында дуңгызлар һәм мөгезле эре терлек симертү буенча ярдәмче хуҗалыклар оештырылды, ниһаять, Егоркино авылында кибет төзелеше тәмамланырга тиеш.

БОРЧЫЛА, чөнки товарларның барлык төре буенча фондларның капланмавы күзәтелә һәм гади кибетчедән алып директорга кадәрге һәркемнең төп бурычы—товар табу чыганагын эзләп, товарлар кайтару. Икенче сүзләр белән әйткәндә, 7 миллион сумлык товар алып җиткерелмәде. Моннан тыш бүгенге көндә сатуда чәй юк һәм аны кайдан алырга да юк. Сыйфатлы колбаса чыгару өчен компонентлар да җитешми.

УҢАЙСЫЗЛАНА, чөнки ярдәмче хуҗалыкларда җитештерелгән ит башка предприятиеләрдәге кебек льготалы бәягә эшчеләргә һәм хезмәткәрләргә сатылмый, азык комбинатына эшкәртергә җибәрелә. Сәүдә работникларының хезмәте тиешенчә бәяләнми. Ә бит алар ял һәм бәйрәм көннәрендә дә эш урыннарында булалар. Шәһәрне су белән начар тәэмин итү җәмәгать туклануы предприятиесе һәм хәзерләүләр конторасы эшен катлауландыра, ә авыл хуҗалыгы идарәсе хәзерләүләр конторасын ягулык белән начар тәэмин итә. Иң мөһиме—бүген хәзерләнгән йомырка һәм ит продуктларын сату мөмкин түгел.

ПЛАНЛАШТЫРА: куәтле котельня төзелешен, азык комбинаты каршында 8 фатирлы торак йортны, Якушкино һәм Үрнәк авылларында кибетләрне файдалануга тапшыруны, Бикүле һәм Әмзә авылларында икмәк пешерү пекарнясын тапшыруны файдалануга бирүне.

ГАФУ ҮТЕНӘ: чөнки халыкка хезмәт күрсәтүдә (бигрәк тә авыл җирләрендә) өзеклекләр туа. Сәбәбе—барлык сатучыларның да чөгендер эшкәртүдә катнашуында.

Райпо подразделениеләренә әлеге культура 190 гектардан артык беркетелгән.

ГОРУРЛАНА: биредә азык комбинатының суган киптерү цехы начальнигы Н. В. Литта, эчемлекләр бүлү цехы мастеры Ф. И. Фәтхетдинова, колбаса ясау цехы начальнигы З. Л. Мусатова, шулай ук эшчеләр Н. И. Яруллина, Р. Х. Абдрахманова, Н. Хәйдәрова, Л. Миронова, Мамык кирпеч заводы директоры М. С. Моратов, җәмәгать туклануы предприятиесенең поварлар бригадирлары Р. Г. Гайнуллина, Л. В. Орешина, Ф. Шәяхмәтова, С. Ганиева, буфетчылар С. Җамалиева, З. Ибәтуллина, Д. Рәхмәтуллина, сатучылар В. Рогожина, Н. Гозәерова, М. Манәпова, В. Агафонова, хәзерләүчеләр Ш. Х. Шәйхетдинов, Г. Мортазин, тире чималы склад эшчесе В. Иванова, икенче чимал склады эшчеләре В. Шәйдуллина, Н. Волкова һәм тагын бик күп карусыз, үзләренең өсләренә төшкән бурычны намус белән үтәүче, вакыт белән исәпләшмәүчеләр горурлык хисе уята.

СОРЫЙ: Потребкооперация работникларының профессиональ бәйрәме көнне барыгызның да игътибарлы, ягымлы булуыгызны сорыйбыз. Шуны да онытмагыз, сатучы да бит башкалар кебек үк кеше.

ТӘКЪДИМ ИТӘ: сәүдәгә башка күзлектән карарга өйрәнергә кирәк. Чөнки бик күпләр биредә үзгәрә, яңара.

Райпо коллективы тату. Шуңа күрә эш тә җайлы бара. Подразделениеләр арасында үзара мөнәсәбәт яхшы. Барлык эшләр белән дә райпо идарәсе шөгыльләнә, ә аерым шәхесләр түгел. Уңышка гарантия дә әнә шунда.

ТЕЛӘК БЕЛДЕРӘ: барыгызга да сәламәтлек, гаилә бәхете, ә иң мөһиме хәзерге киеренке чор тизрәк үтсен иде.

**Безнең махсус корреспондентыбыз райпо идарәсе рәисе Һ. Х Садыйков, шулай ук аның сәүдә буенча урынбасары Ф. Н. Гобәйдуллин, азык комбинаты директоры В. Ә. Ибраһимов, хәзерләүләр конторасы начальнигы Ә. Шәйдуллин, җәмәгать туклану предприятиесенең производство мөдире Т.П. Абдушева белән сөйләшкәч әнә шундый нәтиҗәгә килде.**

**Газетаның 60 еллык юбилее уңае белән аның чираттагы саны 5 июльдә—җомга көндә чыгачак.**

Кечкенә интервью

# Җир үзенә тарта

**Район Советы каршында оештырылган җир комитеты әле күптән түгел генә эшли башлады сыман. Әмма ул вазифаларын үзләштерергә өлгерде инде. Аның тәүге мәшәкатьләре турында сөйләүне үтенеп, без комитет рәисе Р. Х. ХӘСӘНОВКА мөрәҗәгать иттек.**

—Быел район оешмалары, предприятиеләре күмәк бакча оештыру максатында 281 гектар җир алдылар. Бу—5141 гаилә бакча участогы белән тәэмин ителде дигән сүз. Аның иң күбе—59 гектар «Норлатнефть» НГДУсына, 56 гектары шикәр заводына,16 гектар НУРБга туры килә.

Моннан тыш бәрәңге утырту өчен 362 гектар җир бүленде. Соңгы вакытта дача өчен участоклар алу да күбәйде. Ел башында бу үтенеч белән кергән гражданнарны канәгатьләндерү өчен 23 гектар җир җитми калган иде. Инде Мичурин исемендәге колхоз белән сөйләшеп, әлеге максатларда 27 гектар җир бүленде. Дача участогы алырга теләүчеләр җир комитетына мөрәҗәгать итә алалар.

**—Рифкать Хатыйпович, исегездә булса, сез газета корреспондентына 11 апрель санында биргән интервьюда «әлегә бездә җир алган аерым крестьян хуҗалыгы юк»,—дигән идегез. Сез моңа яңалык өсти алмыйсызмы?**

—Мин моны канәгатьлек белән өстим. Хәзер безнең районда 5 крестьян хуҗалыгы исәпләнә, аларга гариза нигезендә файдалануга җир бирелде. Иң зур хуҗалыкларның берсе —Хәниф Даутовның «Шомыртлык» хуҗалыгы, 5 кешене берләштергән бу хуҗалык 106 гектар җир алды, аның 68 гектары—сөрү җире. Хуҗалык киләчәктә ит-сөт җитештерү юнәлешендә үсәчәк. Аларның гаризасы район Советы президиумында каралды, җирдән файдалану акты бар, хәзер алар банкта үз счетларын ача алалар, шулай ук республиканың «Крестьян хуҗалыклары ассоциациясе»ндә кирәкле техника, инвентарь алуга чиратка баса алалар.

Шундый ук икенче хуҗалык «Сөлчә» совхозында Брейн-Ринг»дип атала.Аның җитәкчесе Николай Иванов, алар 3 әү 21 гектар җир беркеттеләр.

«Знамя Октября» колхозының үзендә генә дә 2 хуҗалык исәпләнә: Иван Ерофеевның ике кешелек (хатыны белән) «Надежда»хуҗалыгы 25 гектар җир алды, ул сарыкчылык белән шөгыльләнәчәк. Александр Тумаков энесе белән 5 гектар җир беркетте, аларның «Факел»ы да ит терлекчелеге белән шөгыльләнәчәк. Хәзер «40 лет Победы» колхозыннан Сабир Хәбибуллович Хәбибуллиннар да үз теләкләрен тормышка ашырып йөриләр. Эш шунда: 8 кеше, нигездә туганнар берләшеп, 153 гектар җир алып (аның 59 гектары урман), крестьян хуҗалыгы оештырырга ниятлиләр. Киләчәктә ул мөгезле эре терлек үстереп, аны сатарга, үзенчәлекле махсус хуҗалык булдырырга ниятли. Хуҗалык членнарының умартачылык белән шөгыльләнергә дә ниятләре юк түгел.

«Комбайн» колхозында исә 2 хуҗалык берләшеп «Крестьян хуҗалыклары союзы» төзергә телиләр. Алар үз карамакларына 269 гектар җир алырга, аны даими файдалану өчен беркетергә ниятлиләр. Әлегә алар оештыру стадиясендә генә, әмма егетләрнең яңага омтылышы мактауга лаек.

**Моннан тыш мәшәкатьләрегез дә бармы?**

—Алар аз түгел. Оешмалар, предприятиеләр ярдәмче хуҗалыклар булдырырга да ныклап алындылар. Соңгы вакытта Норлат геофизик эшләр идарәсе Кузнецов исемендәге колхозда,хуҗалыкара төзелеш оешмасы «Знамя Октября» колхозының Петровский поселогында шул мәшәкатьләрне киң җәелдерделәр. Болар һәммәсе кешеләрне җиргә тарту, аңа хуҗа булу хисе тәрбияләүдә булышыр дип уйлыйбыз.

**—Сезгә изге ниятегездә уңышлар телисе генә кала.**

Әңгәмәне
**С. ХӘЙРУЛЛИНА**
алып барды.

# Слесарь Васин

Геннадий Иванович ремонт-техник предприятиенең иң җаваплы участогының берсендә эшли. Ул шатун-поршеньнарны һәм терсәк валларын ремонтлый. Барлык дизель двигательләре дә аның кулы аша үтә.

Ремонт-техник предприятиесендә Геннадий Васин унсигезенче елын хезмәт куя. Аның хезмәт хакы эшләгән эшенең сыйфатына турыдан-туры бәйле.

Билгеле булганча, ремонт-техник предприятие үзендә хәзер продукция җитештерми. Ул колхоз-совхозлар хисабына эшли. Шунлыктан аның продукциясе никадәр күбрәк җитештерелсә, хезмәт хакын шул күләмдә арттыру мөмкинлеге юк.

Хезмәт хакы дигәннән, ни өчен мин аңа аерым тукталдым. Һәрберебезгә мәгълүм, хәзер товарларга бәя икеләтә артты. Ә Васиннарга ничек яшәргә? Алар бу кыенлыктан чыгуның кайбер юлларын эзләп тапканнар. «Төрнәс» совхозында Геннадий үзе туып-үскән ташландык йортны рәткә китерә, аны дача итеп тота башлый. Үзләренә бөтенләе белән күчеп килгән әниләре Анастасия Максимовна да җәйгә кайтып торырга ризалаша. Шулай итеп, Геннадий Ивановичлар кирәк кадәр бәрәңге, яшелчә утырталар. Аларда җиләк-җимеш тә җитәрлек була, ел саен варенье кайнаталар. Дуңгыз асрыйлар, шуңа күрә итне дә сатып алмаска тырышалар. Аннан ремонт-техник предприятие администрациясе эшчеләргә бәясе 3 сумнан ит сатып бирә. Зарарлы эштә эшләүләрен дә искә алып, көненә ярты литр сөт бирәләр.

Слесарь Геннадий Иванович Васин үзе эш шартларыннан канәгать.

—Хезмәтем җиңел түгел, ләкин эшләр өчен бөтен мөмкинлекләр дә бар,—ди ул.

Соңгы сүз итеп шуны әйтергә кирәк, киләчәктә Васин кул астында һөнәр үзләштергән яшьләр биредә ныклап тамыр җәеп калырлар дип ышанасы килә.

**Г. РИЗАТДИНОВА.**

● Авыл проблемалары

# Хатын-кызларның борчылулары

«Хәзер газета битләрендә дә, теле-радио тапшыруларында да кыенлыклар, борчулар турында күп язалар, күп сөйлиләр. Ләкин авыл хатыннарының хәле тагын да аянычрак бит.

Менә уйлап карагыз әле. Чөгендер эшлиме, сыер савамы, дуңгыз, сарык карыймы—вакыт белән санашуны белми бит ул авыл хатыннары. Моны бары тик үз җилкәсендә татыганнар гына аңлый ала. Җитмәсә, таңнан төнгә кадәр фермаларда, кырларда эшләү өстенә малтуар тотарга, бакча карарга, гаиләнең бөтенлеген кайгыртырга туры килә. Шәһәрдәгеләр ике яки өч бүлмәле фатирын чистартып «өф» итеп кенә тота. Ә безгә суын да Чирмешәннән, я коедан ташырга, утынын, ташкүмерен кертеп мич тирәсендә дә кайнашырга туры килә, авылда йорт хуҗалыгы да күп көч сорый бит.

Матур итеп, кеше күзе төшәрлек итеп елына икеөч кунакка барганда гына киенә алабыз, башка вакытта бу хакта уйлап буламы соң, безнең кием—бишмәт тә резина итекләр...»

Шулай диюләре белән сыер савучылардан Галия Гатауллина, Миннеруй Яруллина, Роза Билалова, Нажия Айсина һәм башка савучылар хаклы. Чөнки бу бер ульяновлылар өчен генә түгел, ә ил күләмендәге проблема булып тора.

Матур итеп киенәсе килмимени авыл кешесенең? Килә дә бит, кибетендә тектерергә товары, экче кием-салымы, оек кебек нәрсәләре, пальтолары булмагач нишләсен ул?! Ә балаларны мәктәпкә әзерләү ни тора! Моны бары тик авыл хатыннары гына белә, көчкә буш вакытын табып, балаларын ияртеп йөрүче аналар белән август аенда район үзәге мыжлап тора. Кибеттән кибеткә йөреп хәлдән таялар, ләкин кирәкле әйбер юк, ә бит шәһәрнең үзендә дә шул проблема.

Сәүдә хезмәткәрләре хезмәт кешесенең вакытын да, җанын да кадерләрлек заманалар килер микән—әнә шундый уйлар борчый авыл кешеләрен.

Ә суыткыч, телевизор, магнитофон ватылса, тагын Норлатка чыгып китәргә туры килә. Соңгы елларда диван, тахта һәм башка җиһазлар өчен килеп туган чын-чынлап җәнҗал, үпкә, әрнүләр күңелне күпме җәрәхәтли бит.

Бездә бит әле аның медицина эшенең куелышы да мактанырлык түгел. Авыл кешеләренә һич тә авырырга ярамый. Беренчедән, вакыт юк, икенчедән больничный лист артыннан тагын ничәмә чакрымнар еракльктагы участок больницасына барырга кирәк. Җирле медпункт аны бирми—хаклары юк.

Шулай да көчең бар чагында тырышасың, тырмашасың, җаен табасың. Ә менә олы яшьтәгеләр бөтенләй авыр хәлдә, аларны күреп күңел сыкрана. Чөнки алар авылда күбәя бара, ә яшьләр шәһәр ягын каера, авылда калмый. Сугышның бөтен авырлыгы, аннан соңгы ачы заманалар алар өстендә булды, хәзер ни көчләре, ни сәламәтлекләре юк, үзләре дә, йорт-җирләре дә бетерешкән. Бер кибеткә барып кайтуы гына ни тора, ә хәзерге ни сорасаң шул юк заманда ничә көн рәттән йөрергә туры килә.

Менә шундый һәм тагын башка бик күп проблемалар борчый авыл хатыннарын. Бу уңайдан райондагы һәм колхоздагы һәрбер җитәкчелек хатын-кызлар хәлен җиңеләйтүдә эшлекле чаралар күрсен иде. Авылларыбызда һәм район буенча хатын-кызлар советлары бар бит. Бу яктан аларның эшен дә нәтиҗәле дип булмый әле. Аларны җанландырасы, хәтта бөтенләй сугышчан оешма итәсе иде. Үз проблемалары, үз борчулары өчен алар башлап йөргәндә генә һәртөрле мәсьәләләрнең чишелешен тизләтү мөмкин булачак.

**В. ӘХМӘТҖАНОВ.**



## *Рәхимовлар нәселеннән*

**Рәхимовлар,механизаторлар династиясеннән ул. Сабыр холкы, эшне җиренә җиткереп башкаруы белән дә гел аларга охшаган. Техниканы белүе, аны кадерләве дә нәкъ аларныкы—олы Рәхимовларныкыча. Илгиз Рәхимов хәзер Илдус абыйсыннан тәҗрибәдә дә, егәрлектә дә калышмый. Чөнки мәктәпне бетергәннән бирле—20 ел инде «Алга»колхозында механизатор булып эшли ул. Абыйларыннан алган беренче киңәшләрне үз тәҗрибәсе белән баетырга, ныгытырга өлгерде. Кышларын «Беларусь» тракторында эшли, ә җәйләрен кыр корабына утырып ашлык җыючыларга кушыла. Быел да аның нияте шундый. Хәзер үз комбайнын җаваплы бәйгегә әзерли. Исәбе— сынатмаска, Рәхимовларча эшләргә аның.**

**Рәсемдә: «Алга» колхозы механизаторы И. А. Рәхимов.**

**В. Никонорова фотосы.**

# Кешеләргә бәхет өләшә

Хат ташучы һөнәрен берәүләр җиңелгә санныйлар. Аны сез Салдакай авылыннан Сания Мостафинадан сорагыз. 30 ел колхоз производствосында эшләгәннән соң керешкән иде ул хат ташучы вазифасына. Инде менә 5 ел шул хезмәттә булды. Яңгырында да, карында-салкынында да, җәйге челләдә дә аның җилкәсеннән авыр почта сумкасы төшмәде. Алай гынамы әле? Башка хат ташучылардан аермалы буларак, ул көнлек корреспонденцияне күрше Якушкино авылыннан барып ала. Еш кына бу араны аңа җәяү үтәргә туры килә. Ә бит хәзер хат ташучыга акча переводларын, пенсияләрне, компенсацияләрне тарату да йөкләнгән. Бу байтак сумма җыела. Сания апа аларның һәммәсен зур төгәллек, җаваплылык белән башкарып килә.

Ул биш бала тәрбияләп үстергән, иптәше белән аларны кеше иткән. Шушы көннәрдә Сания апага 50 яшь тула. Хат ташучы балаларыннан, оныкларыннан котлау-тәбрикләүләрне аз алмагандыр. Аларга без дә кушылабыз, аның кешеләргә шатлык өләшүче хезмәтен дәвам итүен телибез.

**И. ЛОТФУЛЛИНА,**
район элемтә узелы экономисты.

**РӘСМИ ХРОНИКА**

29 июньдә «Игенче» колхозы колхозчыларының гомуми җыелышында хуҗалыкның рәисе итеп «Татарстан» колхозы партия оешмасы секретаре булып эшләгән РИФКАТЬ ӘХМӘДУЛЛА улы НАСЫЙБУЛЛИН сайланды.

